КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 март г.Казань № 227

2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм коммерциягә карамаган оешмаларның Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 24 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин